**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлегенең Олы Саурыш торак пунктында гражданнар җыены буенча**

**2019 елның 7 декабре** **Олы Мишә авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мишә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,2019 елның 7 декабрендә Олы Саурыш торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлегенең Олы Саурыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Олы Саурыш авылында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

-су башнясы өчен тирән насос алу;

- Г. Хәбибуллин урамы буенча юлга вак таш җәю;

- юлларны кардан чистарту;

- урам яктырткычлары, энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;

- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру?»

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 77 кеше кертелгән;
җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 51 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында катнашкан 51 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлегенең Олы Саурыш торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2.Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлегенең Олы Саурыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Олы Саурыш авылында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

-су башнясы өчен тирән насос алу;

- Г. Хәбибуллин урамы буенча юлга вак таш җәю;

- юлларны кардан чистарту;

- урам яктырткычлары, энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;

- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру

- кабул ителгән.

3. Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны, гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән, мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Олы Мишә авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Олы Мишә авыл җирлеге Башлыгы: Г. Ә. Маннапов